ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 7 – 8) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:
“$3^1$) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга таләпләр билгеләү;”;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^1$ пункт өстәргә:
“$7^1$) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга таләпләр билгеләү;”;

3) 7 статьяның 6 өлешендә:
а) 1 пунктта “, ә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм

багаж ташуның регионара маршрутлары буенча гамәлгә ашырылган очракта, рәттән кимендә биш рейс үтәлмәсә” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән очракта – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты белән, муниципаль норматив хокукый акт белән билгеләнгән җайга салынмый торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга таләпләрне бер ел эчендә кабат бозган очракта.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 20 июль
№ 59-ТРЗ